**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Ключи авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Олы Покровка авылы**

**2025 елның 26 октябре № 2**
**13.00**
**Олы Покровка авылы,**
**балалар мәйданчыгының янәшәдәге территориясендә**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Олы Покровка авылы торак пунктында гражданнар җыены

карар кылды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Олы Покровка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, мобилизацияләнгән гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең традицион күмү урынын ремонтлау, коймаларны кору, төзекләндерү (иске койманы сүтү, төзелеш материаллары сатып алу һәм Олы Покровка авылы зиратын яңа койма белән әйләндереп алу).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**«Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы**

**__________ А. Н.Карпухин**